КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 февраль г.Казань № 108

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кайбер социаль хезмәт күрсәтү оешмалары койка фондын билгеләү турында» 2015 ел, 17 апрель, 257 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кайбер социаль хезмәт күрсәтү оешмалары койка фондын билгеләү турында» 2015 ел, 17 апрель, 257 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 6 март, 119 нчы, 2021 ел, 30 декабрь, 1366 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып), 1 пунктның икенче – җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Яңа Чүриле социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 413 ятак-урын күләмендә;

«Алабуга социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 460 ятак-урын күләмендә;

«Зеленодольск социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 544 ятак-урын күләмендә;

«Чистай социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 286 ятак-урын күләмендә;

«Казан социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 337 ятак-урын күләмендә;

«Кама Аланы социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 440 ятак-урын күләмендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин